ГЛАВА ДЫМ-ТАМАКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
с.Дым-Тамак, ул.Новая, д.4в, 423955

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ДИМТАМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Димтамак авылы, Яна урам, 4 в йорт, 423955

Тел.:(85593) 4-52-37, факс:4-52-37, e-mail: Dtam.Utz@tatar.ru

**Постановление** **Карар**
**№ 11** **2020 ел 14 ноябрь**

Ютазы муниципаль районыДим-Тамак авыл җирлегенең Ак-Юл торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, 2019 елның 17 июлендә кабул ителгән Ютазы муниципаль районы Дим-Тамак авыл җирлеге Уставының 14 маддәсе нигезендә, К А Р А Р И Т Ә М:

1. 2020 елның 12 ноябренә 10 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Дим-Тамак авыл җирлеге, Ак-Юл авылы, Лесная урамы, 11 санлы йорт каршында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын оештырырга.
2. Халык җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

Ютазы муниципаль районы Дим-Тамак авыл җирлеге Ак-Юл авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъльк яшенә җиткән, балачактан инвалид булган, I һәм II төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән тыш, 2021 елда 400 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм әлеге акчаларны җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга сез ризамы:

- Ак-Юл торак пунктында Лесная урамы буенча юл-урам челтәрен норматив хәлгә китерү (төзелеш, реконструкция, ремонт, вак таш салу, җәю, ташу, төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);

« ӘЙЕ» «ЮК».

3. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы "Димтамак авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге башлыгының 2020 елның 2 ноябрендә кабул ителгән “2021 елда Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлегенең Ак-Юл торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында” гы 2 санлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
4. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә, http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында», www.yutaza.tatar.ru веб-адрес буенча Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә кабул ителгәннән соң 5 көн эчендә урнаштырырга.
5. Әлеге карар халыкка җиткерелгән көненнән үз көченә керә.

Ютазы муниципаль районы
Димтамак авыл җирлеге башлыгы Җ.А.Хөснетдинов